**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Иркәнәш авыл җирлеге составына кергән Кызыл Төбәк торак пунктында
халык җыены нәтиҗәләре турында

**13.11.2020ел.** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 13 ноябрендә узган халык җыены нәтиҗәләре белән халык җыенының йомгаклау беркетмәсе түбәндәге мәсьәлә буенча төзелде: "2021 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлегенең Кызыл Төбәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә (1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, БВС ветераннарының тол хатыннары, тыл хезмәтчәннәре, көндезге бүлектә укучы студентлар, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнадан тыш) үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә Сез ризамы?":

- Кызыл Төбәк торак пунктында зират коймаларын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, койма кою, эшләр өчен килешү нигезендә түләү).

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган катнашучылар исемлегенә 92 халык җыенында катнашучы кертелгән, халык җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны - 58 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
җыенда катнашкан 58 кеше «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар бирде:

1.Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлегенең Кызыл Төбәк торак пунктында халык җыены узуын таныргa, халык җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип таныргa.

2. "2021 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлегенең Кызыл Төбәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә (1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, БВС ветераннарының тол хатыннары, тыл хезмәтчәннәре, көндезге бүлектә укучы студентлар, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш) үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә Сез ризамы?" мәсьәләсе буенча карарны таныргa:

- Кызыл Төбәк торак пунктында зират коймаларын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, койма кою, эшләр өчен килешү нигезендә түләү).

3. Иркәнәш авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен кабул ителгән көннән 7 көн эчендә Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында (https://menzelinsk.tatarstan.ru) хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Иркәнәш авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

**Халык җыенында рәислек итүче,**
**Минзәлә муниципаль районы**
**Иркәнәш авыл җирлеге башлыгы** **Камалов И.З.**